**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 26 декабрендәге ПУ-699 номерлы Указы нигезендә хупланган (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 декабрендәге ПУ-809 номерлы һәм 2012 елның 4 августындагы ПУ-641 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына, аны әлеге Указга кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 29 июль
№ ПУ-681

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «29» июлендәге
ПУ- 681 номерлы
Указына кушымта

## Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасы

**Министр**

Ярдәмче

Кадрлар бүлеге

Матбугат секретаре

Икенче бүлек

Юридик бүлек

Эшләр идарәсе
- Гомуми бүлек
- Гражданнар хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү секторы

### Министрның беренче урынбасары

Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе
- Дәвалау ярдәме бүлеге
- Балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм бала тудыруда һәм тудыргач ярдәм итү хезмәте бүлеге
- Профилактика ярдәме һәм сәламәтлекне ныгыту бүлеге

Югары технологияле медицина ярдәмен оештыру бүлеге

Казан, Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге территориаль идарәләр

### Министр урынбасары

Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсе
- Бюджет акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге
- Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе чаралары буенча икътисадый анализ бүлеге
- Дәүләт гарантияләре программасын исәпләү бүлеге

Махсус программалар һәм проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру бүлеге

Бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторы

### Министр урынбасары

Медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын контрольдә тоту идарәсе
- Медицина эшчәнлеген һәм медицина экспертизалары сыйфатын ведомство контролендә тоту бүлеге
- Стандартларны кертү һәм мониторинглау бүлеге
- Медицина белеме бирү һәм аттестацияләү бүлеге

Мәгълүмати һәм инновацион технологияләр бүлеге

Мәгълүматны саклау секторы

### Министр урынбасары

Фармация идарәсе
- Дарулар белән тәэмин итүгә идарә бүлеге
- Дарулар куллану өлкәсендә җайга салу бүлеге
- Дәүләт заказын җайга салу бүлеге

Медицина техникасы бүлеге

Мониторинглау һәм сәламәтлек саклауны ресурслар белән тәэмин итүне анализлау

### Министр урынбасары

Лицензияләү идарәсе
- Медицина эшчәнлеген лицензияләү бүлеге
- Фармация эшчәнлеге һәм наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм прекурсорлар әйләнеше буенча, составында наркотик матдәләр булган үсемлекләр үстерү белән бәйле эшчәнлекләрне лицензияләү бүлеге

Ведомство карамагындагы учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү һәм контроль секторы

Сәламәтлек саклауның беренчел буынын үстерү секторы

---